Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

КАРАР

2024 елның 27 ноябре № 50/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 февралендәге 34/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Баганалысы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау турында» 2023 елның 10 февралендәге 34/1 номерлы Чистай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Баганалысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 9 пунктында:

1.1.1. 6 пунктчада «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча,» сүзләрен өстәргә;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле яңа 9 пунктча өстәргә:

«9) бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгели.».

1.2. 5.1 статьяда:

1.2.1. 10 пунктта «242_25 һәм 242_26 статьялары белән» сүзләрен «24_4 бүлеге белән» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2.2. 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актында билгеләнгән очракларда һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә җирлекнең финанс органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_26 статьясының 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән акчаларны киңәйтелгән казначылык озатып йөрүен гамәлгә ашырырга хокуклы.»;

1.3. 38 статьяда:

1.3.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«-бюджет ассигнованиеләре ашыгыч гуманитар җавап бирү, гуманитар ярдәм йөкләрен китерү, халыкны эвакуацияләү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын финанс белән тәэмин итүгә яңадан бүленгән очракта.»;

1.3.2. 3 пунктның соңгы абзацында «норматив йөкләмәләрне» сүзләреннән соң «(Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 217 статьясындагы 7 пунктының егерме бишенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Җаббаров